**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423004, с. Старые Челны, ул. Ленина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

423004, Иске Чаллы авылы, Ленина ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Чаллы ав. **КАРАР**

**«26» октябрь 2022 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1.. 2022 елның 7 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылы Чапаев, Синдряков урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 7 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылы Совет урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2022 елның 7 ноябрендә 14сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылы Гагарин, Ленин һәм Мәктәп урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2022 елның 8 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Тынычлык, Яшьләр һәм Хастаханә урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Иске Чаллы торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Чаллы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау;
- Иске Чаллы торак пункты чикләрендә юлларда чокырларны ямау:

« РИЗА» «КАРШЫ» ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров